**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422650, пгт. Рыбная Слобода,
ул. Ленина, дом 48

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422650, Балык Бистәсе,
Ленин урамы, 48 нче йорт

Тел.: (84361) 22113, факс: (84361) 23012, e-mail: balyk-bistage@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

26.04.2017 Балык Бистәсе штп. № 82пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты исеменнән Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә объектларны төзүгә һәм файдалануга тапшыруга рөхсәткә кул куярга вәкаләтле вазыйфаи затлар турында

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә объектлар төзүгә һәм файдалануга тапшыруга рөхсәт язуга вәкаләтле җирле үзидарәнең вазыйфаи затларын билгеләү максатларында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә, КАРАР БИРӘМ:
1.Билгеләргә:

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесен-Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты исеменнән вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә объектларны төзүгә һәм файдалануга тапшыруга, юридик затларга, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясындагы 5-6 өлешләрендә, 55 статьясындагы 2, 5 өлешләрендә билгеләнгән очраклардан тыш, юридик затларга бирелә торган рөхсәтнамәләргә кул куярга;

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлеге башлыгын Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты исеменнән физик затларга, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясындагы 5-6 өлешләрендә, 55 статьясындагы 2, 5 өлешләрендә билгеләнгән очраклардан тыш, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә объектларны төзү һәм файдалануга тапшыру өчен рөхсәткә кул куярга.

2.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вакытлыча булмаганда (авыруга яки ялга бәйле рәвештә), аның вәкаләтләрен вакытыннан алда туктатканда йә суд карары буенча процессуаль мәҗбүри итү чараларын кулланганда, аның вәкаләтләрен вазыйфаларны билгеләнгән бүлешү нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарларының берсе башкара дип билгеләргә.

3.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлеге башлыгы вакытлыча булмаганда (авыруга яки ялга бәйле рәвештә), аның вәкаләтләрен вакытыннан алда туктатканда йә суд карары буенча аңа процессуаль мәҗбүри итү чараларын кулланганда, вакытлыча сак астына алу яки вазыйфадан вакытлыча читләштерү рәвешендә аның вәкаләтләрен вәкаләтле муниципаль хезмәткәр башкара дип билгеләргә, ул Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты күрсәтмәсе нигезендә билгеләнә.

4.Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

5. Әлеге карарны Интернет-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru веб-адресы ,Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» нда http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

6.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктур үсеш бүлеге башлыгы Д.А. Низамовка йөкләргә.

Җитәкче Р. Х. Хәбибуллин